**“Татарстан Республикасында балаларны дәүләт телләренә өйрәтүдә яңа укыту методик комплекты куллану системасы”**
**темасына чыгыш-презентация**

**1 слайд.** Без тирән үзгәрешләр һәм социаль – икътисади үзгәртеп корулар чорында яшибез. Белем бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия учреждениеләренең эше дә көннән-көн яңара, матур традицияләргә байый. Без, педагоглар, яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем бирүнең нәтиҗәле алымнарын эзлибез. Балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә зур игътибар бирәбез. Тәрбия һәм белем бирү эшендә бертөрлелектән арына барып, заман таләпләренә җавап бирә торган программаларны, яңа технологияләрне көннән – көн киңрәк кулланабыз.

**2 слайд.** 2012 елдан башлап Татарстан буенча балалар бакчаларында рус телле балаларга татар телен өйрәтүдә “Татарча сөйләшәбез” дип исемләнгән яңа укыту методик комплекты кулланыла башлады.

**Укыту методик кулланма (УМК) өч проекттан тора:**
**Беренче проект “Минем өем”**
4-5 яшьлек балалар (уртанчылар төркеме) өчен.
**Икенче проект “Уйный – уйный үсәбез”.**
5-6 яшьлек балалар (зурлар төркеме) өчен.
**Өченче проект “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” 6-7** яшьлек балалар ( мәктәпкә әзерлек төркеме) өчен.

Һәр проектка 60 ар эшчәнлек конспектлары төзелгән, максат, бурычлар куелды:

**3слайд.**
**Һәр проект өчен:**
1) тематик план;
2) эшчәнлек конспектлары;
3) балалар өчен эш дәфтәрләре;
4) аудиоматериаллар;
5) анимацион күренешләр;
6) күрсәтмә, таратма материаллар;
7) диагностик материаллар төзелде.

**4 слайд.**
**“Минем өем” проекты.** (Уртанчылар төркеме)
**Максат:** Татар теленә кызыксыну уяту, аралашу теләге тудыру.

**Бурычлар:**
1. Сүз байлыгы булдыру, сөйләмдә активлаштыру.
2. Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.
3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

**Актив сүзләр:**

Әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, зур, кечкенә, матур, туп, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш.

5 **слайд.**

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты**. (Зурлар төркеме)

**Максат:** Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

**Бурычлар:**

1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**Актив сүзләр:**

Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, баллы, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, кирәк, юа, мә, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар, су, хәерле көн.

**6 слайд.**

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты.** (Мәктәпкә әзерлек төркеме)

**Максат:** Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

**Бурычлар:**

1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

**Актив сүзләр:**

Син кем, хәерле көн, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, уйный, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?, сикер, сикерә, сикерәм, йөгер, йөгерә, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь (сиңа ничә яшь?), төлке, тычкан, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, җырлыйбыз, зур рәхмәт, китап укый, укыйм, рәсем ясыйм, дәфтәр, мәктәп, нәрсә яратасың?

**7слайд.**

УМК материаллары һәрберсе киселеп папкаларга, конвертларга урнаштырылды, дидактик уеннар, бармак уеннары да киселеп, ябыштырылып тартмаларга куелды. Һәр төркем өчен татар телендә мультфильмнар, аудиоязмалар кайтты. Шушы материаллар буенча картотека ясалды.

**8 слайд.** Телне өйрәтү процессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә.

Материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик – грамматик материалны балаларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнү өчен күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым.

Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүр. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуын тәэмин ителә.

Икенче телне өйрәнү вакытында бала, ихтыярсыз рәвештә, лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу –телне үзләштерү процессын җинеләйтә. Димәк, һәр эшчәнлеккә программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур. Эшчәнлекләрдә ситуатив кагыйдәләрнең рус һәм татар телендә бирелүе балаларның белем сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора.

**9 слайд.** Безнең балалар бакчасында уртанчылар төркеменнән башлап рус телле балаларга татар теле өйрәтелә. Балалар татар телен бик теләп өйрәнәләр. Уртанчылар, зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркемнәре өчен эш дәфтәрләре әзерләнгән. Бу дәфтәрләр – заманча төзелгән укыту-методик комплектының төп юнәлешләренең берсе булып тора. Эш дәфтәрләрендәге биремнәрне үтәү, татарча мультфильмнар карау, аудиоязмаларга кушылып кабатлау һәм җырлау, уен ситуацияләре, дидактик уеннар балаларга бик ошый. Яңа технологияләр, УМК кулланып эшләү рус телле балаларны татар теленә өйрәткәндә үзенең нәтиҗәле булуын күрсәтә.

Заман үзенең таләпләрен алга китереп куйды, инде математика, сөйләм үстерү һ.б. шөгыльләрдә балалар белән эшләү өчен дәфтәрләрне күптән кулланса лар да, татар телен өйрәтүдә бу яңа чара буларак кабул ителә. Аларның төп бурычлары:

-балаларга яңа лексиканы үзләштерү һәм хәтердә калдыруны җиңеләйтеп, татар теленнән материалны ныгыту;

-балада мөстәкыйль шөгыльләнү өчен теләк тудыру.

Дәфтәрдәге эшнең нәтиҗәсе уртанчылар төркемендә сүзне ишетеп, аңлап, предметларны табып, парлаштырып, чагыштырып, аларның сыйфатын, санын билгеләүгә китерсә, зурлар төркемендә балаларны үзара аралашуга этәрә һәм бу мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә дәвам итә. Иң катлаулы биремнәр мәктәпкә әзерлек төркеме өчен төзелгән, чөнки монда хәрәкәтне белдерүче сүзләр күп кулланылган.

**10слайд.** Дәфтәрләрдәге рәсемнәр матур итеп эшләнгән. Алар белән эшләү балаларны татарчага гына өйрәтеп калмыйча, аларның акылын һәръяклап үстерегә, үткән материалны, яңа сүзләрне уен формасында ныгытырга ярдәм итә. Биремнәр рус телендә язылганлыктан, аның белән төркем тәрбиячеләре дә, ата-аналар да эшли ала. Балалар эш дәфтәрләрендә эшләгән вакытта бер-берсенә сораулар бирәләр, диалог төзиләр, тәрбияче белән аралашалар. Эш дәфтәрләре балаларга сүз өйрәтү процессын

җиңеләйтә, баланың һәм тәрбияченең көчен һәм вакытын экономияли. Алар үзләренең эшчәнлек вакытында эшләгән дәфтәрләрен өйгә алып кайтып кабатлый алалар.

Мин балаларның әти-әниләре белән дә тыгыз элемтәдә торам. Балаларның материалны ничек үзләштерүләре турында әйтәм, киңәшләр бирәм, тәкъдимнәр ясыйм. Әти-әниләр балаларының татар телен теләп өйрәнүләренә бик канәгать. Эш дәфтәрләрен балаларның өйләренә дә бирәм, алар өйрәнгән материалны бергәләп ныгыталар.

Җөмләләр төзү баланың уйлавын таләп итә, чөнки алар 3-4 сүздән торалар. Мәсәлән: Аю караватта йоклый. Куян чана шуа. Песи бит юа.һ.б.

Мәкпәпкәчә яшьтәге балалар эмоциональ, хәрәкәтчән, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә кабул итә һәм фикерли башлый.

Балалар бакчасы булгач, әкият геройлары, җәнлекләр тулаем кеше тормышындагы хәлләрне кабатлыйлар. Чөнки кешегә генә кайтарып калдырсаң, гел әни йоклый, бабай укый, кыз юына кызык түгел.

Аннан мәктәпкә әзерлек төркеме балаларына әзерләнгән биремнәрнең өченчесе җыр булып бара. Балалар өйрәнгән сүзләрен кабатлап җырлап та куялар.

Мин төркем тәрбиячеләре белән дә тыгыз элемтәдә торам. Эшчәнлек вакытында үткән материалны кабатлау буенча биремнәр бирәм. Бу төркем тәрбиячеләренә балалар белән шөгыльләнергә мөмкинлек бирә.